| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ФЕДОРОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ФЕДОРОВСКИЙ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.03.2023 ел Федоровский ав. № 63

«Җир салымы турында» 2015 елның 12 октябрендәге 8 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Җир салымы турында» 2015 елның 12 октябрендәге 8 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 статьяда түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- Россия Федерациясендә (алга таба - хәрби хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзалары турында Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге территориясендә яшәүче, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары.

Хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзалары дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) хәрби хезмәткәр белән никахта торучы (торучы) ир яисә хатын;

2) 18 яшькә җитмәгән яисә бу яшьтән өлкәнрәк хәрби хезмәткәрләрнең балалары, әгәр алар 18 яшькә җиткәнче инвалид булган булсалар, шулай ук көндезге бүлектә белем бирү оешмаларында белем алучы балалар - уку тәмамланганчыга кадәр, әмма алар 23 яшькә җиткәннән дә соңга калмыйча.».

Россия Федерациясе Салым кодексының 389 статьясы нигезендә салым салу объекты.».

2. Әлеге карарның 1.1 пунктындагы 1.1 пунктчасы нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2021-2022 еллардагы салым чорлары өчен җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. ««Җир салымы турында» 2015 елның 12 октябрендәге 8 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Советы

карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 30 ноябрендәге 53 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Советы карарының 1.2. пунктының 1.2.3. пунктчасын һәм 3 пунктны гамәлдән чыгарырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлегенең http://fedor-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырырга

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Федоровский авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ф.Зәйнуллин